ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422643, д. Полянка,
ул. Механизаторов, дом 3б

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ПОЛЯНКА АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422643, Полянка авылы,
Механизаторлар урамы, 3б нче йорт

Тел.: (84361) 24002, Pol.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 29 гыйнвары Полянка авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пунктынүтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Пенсия фондының 2021 елның 13 гыйнварындагы “2021 елның 1 февраленнән Россия Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган индексацияләү турында”гы СЧ-25-24/270 номерлы хатына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 нче кушымталар нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында” 2020 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарын 2021 елның 1 февраленнәнүз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Полянка авылы, Механизаторлар урамы, 3б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы
Полянка авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сираев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634005219 ПОЛЯНКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Полянка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның 29 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсемуниципаль районының Полянка авыл җирлегендә**
**2021елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1966 |
| 3.Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү(алып бару) | 975 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3483,98 |
| Җәмгысе: | 6424,98 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Олы Елга авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның 29 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегендәире (хатыны), якынтуганнары, бүтән туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан мәет куюныгамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган башка затбулмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсе нигездә (бушлай) күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 542 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1424 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 975 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3483,98 |
| Җәмгысе: | 6424,98 |